**УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМЕНӘ, ЭШ ОСТАЛЫГЫНА ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕНӘ ТАЛӘПЛӘР**

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы:

- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларын һәм аларның әсәрләре хакында;
- милли әдәбиятның нинди чорларга бүленешен;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- әдәби-тарихи барышның төп закончалыкларын һәм әдәби юнәлеш, күренешләрнең төп сыйфатларын;
- төр әдәби-теоретик төшенчәләрне

**белергә**;

- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият тарихыннан һәм теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының аерым якларын, элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын иҗтимагый-тарихи контекстта һәм гомумкешелек кыйммәтләре яктылыгында бәяләү;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын, кайсы чорда язылуын билгеләү, чор әдәбиятына хас сыйфатларны табу;
- бер чорда иҗат ителгән һәм төрле чорларда иҗат ителгән әдәби әсәрләрне чагыштыру;
- әдәби әсәргә карата дәлилле шәхсән мөнәсәбәт белдерә алу;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару **күнекмәләрен** үзләштергән булырга тиеш.

**Бирелгән программа буенча укучыларының тел осталыкларына һәм күнекмәләренә таләпләр**

- **рецептив эшчәнлек**: сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты, чор әдәбияты турында чагыштырып, бәяләп, яттан өзекләр китереп сөйләү; әдәби әсәрнең төрен, жанрын, язучы иҗатының төп хасиятләрен, чор әдәбиятының төп үсеш юнәлешләрен билгеләү һәм фикерне исбатлау; әдәби әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау; әдәби әсәрләрнең тарихи-конкрет һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, әдәбияттагы «үтәли» һәм «мәңгелек» проблемаларны ачыклый алу.
- **репродуктив эшчәнлек**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, башка әсәрләр белән чагыштыра, бәяли алу; чор әдәбиятына кагылышлы мәгълүматларны гомумиләштереп сөйли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.
- **иҗади эшчәнлек**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле укый белү; әдәби әсәрләр, язучы иҗаты, чор әдәбияты, гомумән милли әдәбият буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу;
- **эзләнү эшчәнлеге**: әдәби әсәргә, язучы иҗатына, чор әдәбиятына, милли әдәбияттагы аерым күренешләргә нисбәтле проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әсәр белән башка текстлар, шул исәптән башка сәнгать төрләре арасында ассоциатив бәйләнешләрне күрә алу;
- **тикшеренү эшчәнлеге**: тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү; татар, рус (яки башка халыкларның) әдәбиятларында бер төрдәге темага язылган әсәрләрне чагыштыру, милли үзенчәлекләрен ачыклау; татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбияты мәйданындагы урынын һәм ролен бәяләргә омтылу.

- **Түбәндәге нәтиҗәләр көтелә:**
- Укучылар уку елы ахырына түбәндәгеләрне белергә тиеш:
- укыту предметы буларак әдәбиятның төп эчтәлеген: күпгасырлык әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты турында күзаллау булдыру һәм шуңа бәйле рәвештә әсәрләрне уку һәм өйрәнү, тикшерү-анализлау һәм нәтиҗәләр ясый, бәяли алу.
- укучының активлыгы, мөстәкыйль фикерләве, акыл һәм рухи эшчәнлеге активлашуы, шәхес буларак формалашуы;
- укучының үзен тәрбияләргә, үзе белән идарә итәргә өйрәнүе, алган белем һәм күнекмәләрен тормышта куллана белүе, тормышта үз урынын сайларга әзерләнүе;
- баланың үзаңы үсүе, милләтне, Ватанны яратырга өйрәнүе, горурлык һәм гражданлык хисләренә ия булуы;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү

## ӘДӘБИЯТ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

### 10 сыйныф

**Программаның эчтәлеге**

**Кереш.** XX йөз татар әд-ында илдәге һәм дөньядагы сәяси-иҗтимагый хәлләр, социаль тетрәнүләр. Татар әд-ның яңа жанрларга баюы. Халыкчан әдәби телнең формалашуы һәм үсүе. Язуда ике графика алмаштыруның матур әд. үсешенә тискәре йогынты ясавы. Шәхес культы һәм татар язучылары. Сәясиләштерелгән тоталитар система һәм татар әд.

**XX йөз башындагы татар әдәбиятына күзәтү**

1905-1907 еллар инкыйлабы тудырган шартларда милли әд-ның чәчәк атуы. Язучы һәм милләт язмышы. Стильләр ягыннан баю. Әдәби юнәлешләр. Реализмның төрле тармак-төсләре. Пролетар әдәбият юнәлеше барлыкка килү. Романтизм агымы. Символизм, акмеизм, модернизм өлкәсендәге тәҗрибәләр.

ӘТ: Иҗат методы турындагы төшенчәне киңәйтү.

**Гаяз Исхакый.** Тормыш һәм иҗат юлы.Патша хөкүмәтенә каршы көрәше. Әдипнең милләт язмышы өчен борчылуы, татар милләтенең дини һәм колониаль изелүенә каршы чыгышлары, милли азатлык көрәшендә катнаша башлавы. Исхакыйның көрәш юлы. Беренче әсәрләренең XIX гасыр әд. белән XX йөз башы әд-ына күчеш әсәрләре булуы. Төп проблемалар һәм образлар, язучы әсәрләрендә яңа әд-ның нигезләре салыну. “Ике йөз елдан соң инкыйраз” повестеның татар әд. һәм милләтнең үзаңы өчен әһәмияте. “Тормышмы бу?”, “Мулла бабай” әсәрләре, “Алдым-бирдем”, “Мөгаллим”, “Тартышу”, “Кыямәт”, “Зөләйха” драма һәм комедияләрендә үздырылган милләт язмышы һәм социаль тигезлек өчен көрәш фикерләре. Әсәрләрнең үзеген тәшкил иткән конфликт – иске белән яңа тартышы. Әсәрләрдә милли характерның, милли гадәт-йола үзенчәлекләрнең гәүдәләнеше.

“Теләнче кыз” романының өч кисәгендә төрле иҗат үзенчәлекләре чагылышы. Сәгадәт һәм Габдулла образларында шул заман идеяләренең гәүдәләнеше. Кешене һәрчак сагалап торган бозыклык һәм изгелек, мәрхәмәтлелек, сафлык сыйфатларының үзара көрәшен ышандырырлык вакыйгаларда күрсәтү

“Сөннәтче бабай” повесте. Әсәрнең халыкчан җирлеге. Сөннәтче картның рухи дөньясы, рухи кичерешләренең нечкә борылышлары, гадәт-йолаларга тугрылыкның кеше рухын матурлавы, кешене кеше итеп яшәтүе һәм шәхес буларак күтәрүе.

**Ф.Әмирхан“**Хәят” повесте. “Хәят” повестенда бай татар зыялыларының гаилә тормышы һәм гореф-гадәтләре. Шул шартларда үскән татар кызының холкы тәрбияләнү, омтылыш-теләкләре чагылу. Рус дөньясы белән аралашып үскән яшь кешенең дөньяга һәм яшәү тәртипләренә карашында каршылыклар туу, моның ул шартларда мәҗбүрият булуы. Дини йолаларны үтәүнең күңелне сафландыруы, шул ук вакытта дини йола-гадәтләрне тарайтып аңлауның шәхес иреген киртәләүдәге роле. Язучының кешедәге күңел тирбәнешләрен бирүдәге табышлары. ӘТ: Психологик анализ турында төшенчә.

**Г.Ибраһимов**.“Яшь йөрәкләр”. Романда төп сызык. Җәләш, Сабир, Зыя образлары. Кеше җанының матурлыкка сусавын, тынгысыз эзләнүләрен раслаган теләк-омтылышлар. Матурлыкның бер чагылышы буларак музыка. Мәхәббәттә бәхетсезлеккә, шәхеснең фаҗигасенә китергән сәбәпләр. Әсәрнең романтик пафосы, анда сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчан җирлеге. Характерлар сурәтендә психологик бизәкләрнең муллыгы.

**Ш.Камал**. “Акчарлаклар” повесте. Әсәрдә гади хезмәт кешеләре, аларның рухи матурлыгы чагылу. Эчке кичерешләр байлыгы. Бәхет – ни ул? Акчаны мулрак табу – бәхетнең үземе? Бәхет – кешеләрнең саф хисләре, күңелне чистарта торган эш-гамәлләре түгелме? Мондый сорауларга җавап эзләргә этәрүдә әсәрнең исеме; аерым сәнгатьчә детальләр, вакыйгалар бирелеш рәвеше уйнаган роль. Кешеләр язмышында җәмгыять төзелешендәге каршылыклар чагылу.

**Йомгак.** XX йөз башында татар прозасы ирешкән уңышлар. Гомумиләштерү. Күренекле язучылар, аларның әсәрләре. Аларда татар җәмгыятенең тормышы, кешенең, төрле социаль катламнарның бу тормышта урыны һәм кыйммәте чагылу дәрәҗәсе. Әдәбиятка гади кешеләр, хезмәт иясе вәкилләре образлары килеп керү, аларның тормышчан сурәтләнеше. Гуманизмның яңа сыйфатлар алуы.

**XX йөз башы татар поэзиясенә күзәтү**. XX йөз башы татар поэзиясенең яңа баскычка күтәрелүе. Күренекле шагыйрьләр. Гражданлык лирикасы көчәю. Сатира өлкәсендәге уңышлар. Жанр төрләре баю. Сәнгатьчәлек ягыннан казанышлар.

**Г.Тукай.** Тормыш баскычлары. Шагыйрьнең беренче иҗат тәҗрибәләре Яңа фактлар белән танышу. Беренче әсәрләрендәге аваз-мотивлар, кабатлаулар, табышлар. Үзәктә мәгърифәт һәм әдәп-әхлак мәсьәләләре торуы, дидактика принципларын үстерү. Тукай иҗатында халык авыз иҗаты принциплары һәм традицияләрнең көчәюе, җанлы сөйләм теленә якынаю. Риториканың килүе, сурәтлелек арту Тукай шигъриятендә иҗтимагый рухның көчәюе. Социаль тигезлекне гомумкешелек идеалы итеп аңлау, аны төрле яклап раслау һәм яклау. Конкретлаштыру. Милли моңнарга игътибар арту. Шагыйрь һәм чор. Дөньяның һәм яшәүнең мәгънәсен халыкчан позицияләрдән торып аңлату һәм тасвирлау.

Лирик геройның шагыйрь шәхесенә хас билгеләре һәм халыкчан герой белән уртак иткән сыйфатлары. Шагыйрьнең эстетик идеалы. Тукай лирикасы, үзенчәлекләре. Шагыйрь иҗатында табигать, җир, ил, халык образлары. Башка халыклар әдәбиятларына Тукай иҗатының йогынтысы. Тукай – тәнкыйтьче, халык авыз иҗаты һәм милләт тарихы турында хезмәтләре.

**Дәрдеманд**. “Шагыйрьгә”, “Каләмгә хитаб”, “Бүзләрем маналмадым”, “Без”, “Яз чәчәге”, “Гөрләгән сулар башында...”, “Бертуганың чит тибәдер”, “Тел – илнең колагы”, “Ата-анам йорты өчен...”, “Илдә бер дуст булмаса гәр...” шигырьләре. Дәремәнд шигырьләрендә лирик герой. Язмыш фәлсәфәсе. Лирик геройның халык күтәрелешләренә, инкыйлаби үзгәрешләргә мөнәсәбәте. Шигырьләренең сәнгатьчә үзенчәлеге.

**Сәгыйт Рәмиев** Яшьлек елларындагы рухи эзләнүләре. Иҗат эшчәнлегенең башлануы. “Таң йолдызы”, “Тавыш”, газеталарында эшчәнлеге, бу еллардагы иҗаты. Иске тормышны кире кагу. “Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!” һәм “Низамлы мәдрәсә” пьесаларында уздырылган фикерләр; яңа, якты тормышка омтылу, шуңа хезмәт итү, иске, катып калган, милләтне артка сөйри торган тәртипләргә һәм гореф-гадәтләргә каршы булу, көрәшү. Әсәрләрендә мәгърифәтчелек традицияләре. “Таң вакыты” – татар милләтенең уянуына, алга омтылышына ышаныч гимны. Бунтарь рухлылык мотивлары. Ярсулы, шашкын, тынгысыз, хөр фикерле һәм романтик лирик герой.ӘТ: Иҗат методы буларак реализм.

**Мәҗит Гафури.** “Шатлык”, “Көннәребез”, “Электрик фонарена хитаб”, “Түгелгән яшь”, “Татар хатыны”, “Вөждан теләге”, “Юктырсың ла, Алла!”, “Ул кем?”, “Хөррият иртәсе”, “Бер төндә”, “Татар егетенә”, “Эшче”, “Алтын тәре, бәрхет палас”, “Ертылган сәхифәләр” шигырьләре, мәсәлләре. Шагыйрьнең иҗтимагый аң үсеше. Мәгърифәтчелектән – милли азатлыкка, милли азатлыктан иҗтимагый азатлык фикеренә килүе. Иҗатында шәхес иреге проблемасының акрынлап социаль ирек мәсьәләсе белән алмаштырылуы. Поэзиясенең “чорның күзе һәм колагы” булып әверелүе. Вакыт-вакыт гомумкешелек кыйммәтләренең сыйфый мәнфәгатьләр артында күләгәдә калуы. Татулык һәм мәрхәмәт хисләренең үч алу, җәза бирүгә омтылыш хисләре белән аралашып килүе. Болар арасында диалектик бәйләнешне күрү мөмкинлеге. Совет чорында язган әсәрләрендә кеше бәхетен төрле тарафларда эзләве. Сыйнфый көрәшне тарайтып аңлау, вату, җимерү, үч алу мотивлары белән мавыгу, аларны нигезләү. Гафури поэзиясендә лирик герой образы. Рухи азатлык идеяләрендә ышанычның чагылуы. Гафури иҗатының художество үзенчәлекләре. Прозасы турында кыскача мәгълүмат бирү.

**Нәҗип Думави.**“Яз”, “Золым”, “Буш вакыт”, “Татар”, “Үтә, үтә”, “Мәхбүс дустыма”, “Сугыш”, “Син – кеше”, “Сугыш тәэссораты” һ.б. шигырьләре. Думави шигырьләрендә тормышның караңгы, шыксыз якларына җентекле игътибар, “халык кайгысын җырлау”. Иҗтимагый мәсьәләләрнең үткен ралуы, һәртөрле хакимияткә, көчләүләргә каршылыкның ачык чагылышы. Шәхес ирегең буып торган хәлләрне һәм сәбәпләрне сүрәтләү. Шигырьләрдә романтик мотивлар һәм рух; әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр.

**XX йөз башы драматургиясенә күзәтү** Жанрның оешып (формалашып) җитүе, төрләргә һәм жанр формаларына баюы. Татар профессиональ театры туу, төрле группалар оешу. Бу хәлләрнең милли драматургия үсешенә тәэсире. Г.Исхакый пьесалары. “Зөләйха” драмасы. Милләт һәм дин язмышы мәсьәләләренең сәнгатьчә хәл ителеше. Ф.Әмирхан драмаларында яңа һәм искелек көрәше. Шәхес азатлыгы мәсьәләсе. “Яңа кешеләр” образлары. Милләт язмышы проблемасы. С.Рәмиев, И.Богданов пьесаларында искелекне фаш итү, образлар системасы.

М.Фәйзи драматургиясе. “Кызганыч”, “Галиябану”, “Ак калфак” драмаларында шәхес иреге, хокук иреге мәсьәләләренең сәнгатьчә хәл ителеше. Романтик драма тудыру чаралары, романтик пафос һәм геройлар. Драматургиягә килгән яшь көчләр (Ф.Сәйфи-Казанлы, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш). Тематик байлык һәм сәнгатьчә үзенчәлекләр турында йомгак.

**Галиәсгар Камал**. Тормыш һәм иҗат юлы. Мәгърифәт өлкәсендә күпьяклы эшчәнлеге. Беренче пьесалары. Үгет-нәсыйхәт. Сатирик комедияләре. Алардагы төп мәсьләләр, тудырылган типлар. Татар җәмгыятенең кимчелекләреннән көлү. “Банкрот” комедиясе. Сюжеты һәм композициясе, образлар системасы. Акчага омтылышның кешене түбәнлеккә, оятсызлыкка төшерү ихтималы. Кешеләрнең бер-берсенә карата ерткычлыгы, хәрәмләшү, алдашуның җирлеге. Комедиянең әһәмияте, бүгенге көннәргә аваздашлыгы. Драмалары. Мәгърифәтчелек традицияләре булу. Г.Камал драмалары.

ӘТ: Сатира турында тулырак төшенчә бирү. Сатирик конфликт үзенчәлекләре

**Г.Коләхмәтов** – социализм тәгълиматын актив пропагандалаучы. Колахмәтов драмаларының яңалыгы. Бу яңалыкның эчтәлек-фикердә булуы, социалистик идеология алып килүе. Кешенең яшәү мәгънәсен көрәштә күрү, революцион активлыкны яклау. Аллегорик образлар, аларның фәлсәфи эшчәнлеге. Әдәбиятта яңа образлар – эшче, эшче-революционер образлары барлыкка килү. Драматик конфликтның яңалыгы, аның асылда пролетар идеология җирлегендә хәл ителүе. Эшче сыйныф мәнфәгатьләре. Моның фәлсәфи нигезләрен ачыклау. Байлык һәм шәхес, байлык һәм хатын-кыз мөнәсәбәтләренә караш. Татар җәмгыятендә гаять актуаль булган һәм чишелеше табылган бу мәсьәләне язучының пролетар идеология җирлегендә хәл итеп булырына ышанычы чагылу. Драмада психологизм. Сюжет һәм композиция үзенчәлекләре.ӘТ: Пьесаның төзелеше һәм стилистик үзенчәлекләре. Сәхнә әсәрендә сәнгатьчә детальләрнең, ремаркалар, афиша, пауза, репликаларның роле.

**XX йөз башы әдәбиятына күзәтү рухында йомгак.** Бу чордагы балалар әдәбияты, публицистика, әдәби тәнкыйть турында белешмә.

**Совет хакимияте башланганда татар әдәбияты**. 1917 нче елда революцияләр һәм татар язучылары, аларның инкыйлабка килү юллары. Октябрь революциясе идеяләренең татар әдәбиятында чагылуы. Иҗтимагый тигезлек, ирек, сугышны туктату һәм тынычлык өчен җирне крестьяннарга бирү өчен көрәш, гомумкешелек идеаллары рухында кабул итү һәм сурәтләү. Сыйнфый азатлык көрәшен идеаллаштыру. Поэзиядә абстракт һәм космик образ-символларның активлашуы. Иҗтимагый конфликт төп урынны ала. С.Сүнчәләй “Ихтилал шигырьләре”, М.Гафури “Кызыл байрак”, Ф.Бурнаш “Таһир-Зөһрә” трагедиясе. “Яшь йөрәкләр” комедиясе. Сыйнфый тигезсезлекне кире кагу үзенчәлекләре.

**20 нче еллар әдәбияты.** Әдәби процесска характеристика. Яңа газета-журналлар, әдәби төркемнәр һәм агымнар. Яңа тормышның поэтик бизәкләрен һәм сурәтләү телен эзләү. Әдәбияттагы төп темалар. Революция һәм шәхес, кеше, бәхет темасы. М.Гафури, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт шигырь-поэмалары. К.Нәҗми “Шобага”, “Яр буендагы учаклар”. Әдәбиятта Ленин образы. Аны илаһилаштыру, идеаллаштыру. Әсәрләрдә Татарстан темасы. Революцион аскетлык темасы. 20 нче елларда сатира, аның объектлары.

**Галимҗан Ибраһимов**.“Яз башы”, “Диңгездә”, “Сөю-сәгадәт” хикәяләрендә табигать һәм кеше мөнәсәбәтен, табигать гүзәллеген һәм бөеклеген, адәмнең табигать баласы булуын үзенчәлекле итеп, шәхесне югары куеп тасвирлауХарактерлар сурәтендә психологик бизәкләрнең муллыгы“Йөз ел элек”, “Уты сүнгән җәһәннәм”, “Карак мулла”, “Карт ялчы”, “Көтүчеләр”, “Табигать балалары” хикәяләрендә тормышчан кырыс дөреслек. “Көтүчеләр” сүзенә салынган мәгънә. “Безнең көннәр” романы, “Яңа кешеләр” пьесасында төп тема һәм образлар. Совет чорында язган әсәрләрендә сыйнфый тигезсезлекне һәм инкыйлаби көрәшне тасвирлау. Иҗтимагый азатлык көрәшен изгеләштерү, аны кешелекнең бөек омтылышы итеп күрсәтү.

Г.Ибраһимов  “Казакъ кызы” романы. Әсәрнең язылу һәм басылу тарихы. Романның сюжет төзелеше. Яшьләрнең шәхси бәхете дәүләт өчен көрәштән өстен булуы. Биремҗан карт образында милләтнең акылы һәм буйсынмас рухы, иркенлеккә һәм ireккә омтылуы. Казакъ халкының бай рухы, матур гореф-гадәтләре, аерым кимчелекле яклары. Тел-стиль үзенчәлекләре.

Совет чоры әсәрләрендә, публицистикасында, тәнкыйтендә һәм гыйльми хезмәтендә эшче сыйныф идеологиясе үткәрелү. Бу идеологияне берьяклы күпертеп аңлау һәм үткәрергә омтылу.

ӘТ: әдәбиятның интернациональ мәгънәсе, стиль турында төшенчә.Эпиклык.

**Һ.Такташ** Тәрҗемәи хәле, иҗаты, шәхесе. Беренче чор иҗатында гомумкешелек кыйммәтләре чагылу. Мифологик образларга игътибар. Абстракт, дини, мифологик һәм космик образларны чагылдыру. “Такташ үлде”, “Син дә үл инде” манифест рухындагы

шигырьләр. Көрәшче аскетлыгы. Такташ иҗатында яңа реалисик алым-сурәтләр килеп керү һәм активлашу: "Әйдә, энем", "Инде бу кырларда", "Ак чәчәкләр", "Үтеп барышлый". Яшәү мәгънәсен һәм табигать матурлыгын табигать һәм шәхес берлегендә табу

Шагыйрьнең поэзиягә алып килгән яңалыгы ."Киләчәккә хатлар" поэмасы. ӘТ:  Шигырь төзелеше турында мәгълүматларны киңәйтү, бербөтен төшенчә тудыру.

**Ф.Әмирхан. "Шәфигулла агай" .**Әсәрнең язылу һәм саклану тарихы. Вульгар идеологизациянең шәхескә тискәре тәэсирен ачып салу. Шәфигулла образы. Ярдәмче персонаңлар образлары. Яңа җәмгыятьтә торган саен күбрәк урын ала торган примитив тәртипләр, аларның милли гадәт-йолалар белән көлкеле дә, кызганыч та тартыш-бәхәсе, аларны берничә яссылыкта чагылдыру. Повестьның төзелеше, үзенчәлекләре, арттыру алымнары. Әсәрнең совет тәртипләренә һәм вульгар социологизмга бернече үткен сатира булуы. ӘТ: Гипербола, шарж.

**К.Тинчурин**.  Драматургиясе, төп әсәрләре. К.Тинчурин. "Американ" комедиясе. Әсәрдә көлке эчендә көлке бирелүе, конфликтның бу җәһәттән үзенчәлеге. Милләтне артка сөйрәүче иске гореф-гадәтләр. Үз-үзләрен фаш итүгә нигезләнеп сурәтләү үзенчәлекләре. Төп һәм ярдәмче образлар. Әсәрнең төзелеше.ӘТ: Комедия жанры турында бербөтен төшенчә тудыру.

**Йомгаклау.**

**Б**үлекнең төп эчтәлеге:

Ел дәвамында өйрәнгәннәрне үзлектән аңлату. Әсәрләрнең художестволы әһәмияте.

**11 сыйныф**

Чит илләрдә татар әдәбияты. Йосыф Акчура, Хәсән Хәмидулла, Гәүһәр Туганай, Хөсәен Габдүш, Әхнәф Таңгатар, Сания Гыйффәт иҗатлары. Чит илләрдәге татар әдәбиятының торышы турында мәгълүматлы булу. Төп темалар һәм проблемалар, бигрәк тә Туган илне сагыну темасының актуаль булуы. Гаяз Исхакый. Язучының 1917 елгы инкыйлабларга мөнәсәбәте, эмиграциядәге тормышы һәм иҗаты буенча мәгълүматлы булу. Хикәяләре, «Дулкын эчендә», «Ике ут арасында», «Җан Баевич» пьесаларының идея-эстетик үзенчәлекләрен,«Локман хәким» әкияте, «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасындагы төп фикерләрне, тарихи-фәлсәфи эчтәлекнең мөһимлеген, татар әдәбияты өчен яңалыгын аңлау.Г.Исхакыйның "Көз" повесте.Төп образларның сурәтләнүендә эчке мәгънә. Хәлил образына бәя биү. Милли гадәт-йолаларның йомшаруы яки югалуы кешедәге рухи ныклыкка да тәэсир итүен, кешене рухи таркалуга китерүен, башка милләт вәкиленә чит-ят мохитнең аны һәлакәткә дә китерүе мөмкинлеге. Повестьта сәнгатьчә детальләрнең роле, символик образлар.Г.Исхакыйның татар әдәбияты һәм сәнгатендә тоткан урыны.

30 нчы елларда совет әдәбияты. Илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең әдәби процесста чагылышы.

30 нчы елларда иҗади эзләнүләрнең катлаулы, язучылар язмышының фаҗигале булуы. Шәхес культы чорындагы репрессияләр һәм язучылар турында мәгълүмат. Әсәрләрдә заман темаларын чагылдыру үзенчәлекләре; идея һәм сәнгатьлелек принципларында вульгар социологизмның өстенлек итүе. Яңа кеше образын эзләүдә, яңа әхлак нормаларын аңлауда үзенчәлекләрн. Диннең җәмгыять һәм кешелек тарихындагы урынын бозып күрсәтү. Яңа әхлак, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләре үзенчәлекләре (Г.Кутуйның "Тапшырылмаган хатлар" әсәре мисалында). Иҗтимагый идеалны шигъриятькә эверелдерү юлында эзләнүләр. М.Җәлил, Ш.Маннур, Ф.Кәрим, Һ.Такташ шигырьләре. ӘТ :Социалистик реализм.

Н.Исәнбәт.Н.Исәнбәтнең тормыш юлы һәм иҗаты. Н.Исәнбәт "Идегәй" трагедиясе. Трагедиянең кыскача эчтәлеген ача белү, идея-эстетик анализ ясый алу. Татар халкының азатлыкка омтылу рухын чагылдыручы Идегәй образы. ӘТ - Трагедия жанры, трагик конфликт.

40-50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы. 40-50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы һәм татар язучылары. Бөек Ватан сугышының татар язучылары тормышына һәм иҗатына тәэсире.

Ил һәм җәмгыятьнең рухи тормышына сугыш керткән үзгәрешләр. Дошманны җиңүгә омтылыш пафосының әдәбиятта аерым жанрлар үсешенә тәэсире. Партия Үзәк Комитеты 1944 елның августында кабул иткән карар, аның татар әдәбиятына, сәнгать һәм мәдәнияткә ясаган тискәре тәэсире .Әсәрләрдә сугыш һәм кеше проблемасы.

Г.Әпсәләмовның повесть һәм романнары. Аларда романтик сурәтләрһәмобразлар. Сугышфаҗигасенендә, шәхескичерешләренендәтулыачылыпбетмәве. Сугышһәм совет солдаты турында да, илбасарлархакында да берьяклыракмәгълүматбирелү, психологик тирәнлек җитмәү. ӘТ: Роман төрләре.

М.Җәлил.М. Җәлилнең тормыш һәм сугышчан юлы. Сугышка кадәрге иҗаты. «Алтынчәч» драматик поэмасы. «Хат ташучы» поэмасы. Шагыйрьнең сугыш чоры иҗатында батырлык темасының реаль эчтәлек белән сугарылуы. Кеше хисләренең патриотизм пафосы белән тыгыз үрелеп тасвирлануы. М.Җәлилнең ”Моабитдәфтәрләре”.Ватанны саклау сугышында җаваплылык тойгысының төрле поэтик вариацияләре. Дошманга нәфрәтнең чагылышын, сагыну, ярату, якыннарга хөрмәт һ. б. кешелек тойгыларының шигырьләрдә лаеклы урын алуы. Поэтик алымнар һәм бизәкләр, аларның яңалыгы һәм сәнгатьлелек көче.

Ф.Кәрим.«Урман тын иде», «Кереш җыр», «Бездә яздыр», «Теләк», «Юл», «Иптәш», «Мин — гуманист», «Исә җил», «...Сөйләр сүзләр бик күп алар», «Һөҗүм», «Моң һәм көч», «Күл һәм күңел», «Кемне кызганыйм?», «Немец җирендә» шигырьләре,«Гөлсем», «Өмет йолдызы» поэмалары, «Тимер һәм тимерче» балладасы.Ф.Кәримнең тормышы һәм иҗаты.30 нчы еллардагы иҗатында төп темалар. Ф.Кәримнең сугыш елларындагы иҗаты. Батырлыкка рухландырган мәхәббәт хисен югары күтәреп сурәтләү. Сагыну хисен гәүдәләндерү.Сугыш вакыйгаларының, фронт көндәлегенең җанлы күренешләренә ирешү алымнары, поэтик сурәтләр.

ӘТ - Лирик шигырь, поэма, баллада, шагыйрьнеңгражданлыгы.

Татар әдәбияты яңа сыйфат үзгәрешләренә күчеш чорында. 50-60 еллар әдәбиятына күзәтү. Илдә булган хәлләр һәм сәяси-иҗтимагый үзгәрешләр һәм аларның әдәбиятта чагылу дәрәҗәсе. 50-60 нчы еллар әдәбиятының төп иҗат көчләре, аларның әсәрләрендә жанр төрлелеге, сәнгатьлелек ягыннан һәм тематикада яңалыклар.

И.Гази “Онытылмаселлар” трилогиясе. Аерым типик характерлар иҗат итүд әәсәрнең әдәби процесстагы урыны: революцияне кабул итү һәм бәяләүдә кайбер кимчелекләре.

Г.Бәширов “Намус” романы. Әсәрнең хезмәт кешесендәге рухи байлыкны ачуда, тел-сурәтләү чаралары өлкәсендә уңышларын күрсәтә белү. Әсәрнең тормыш дөреслегенә тугрылык ягыннан кайбер җитешсезлекләре.

Х.Туфан.Х.Туфанның тормыш юлы һәм шәхес буларак үзенчәлекле сыйфатлары.«Урал эскизлары», «Бибиевләр» поэмаларындагы төп фикер, сәнгатьчә эшләнешләрендә үзенчәлекләрне белү. Х. Туфанның тоткынлык чорындагы иҗат үзенчәлекләрен белү. Шигырьләрендә моң-зар, хәсрәт-сагыну, фаҗига хис-тойгыларының яңа төсмерләр алуын, күңел төшенкелегенә түгел, яктылыкка, киләчәккә хезмәт итүен,  шигъриятенең фәлсәфи тирәнлеген аңлау.

Х.Туфанның 60-70 нчееллариҗаты. 60—70 нче елларда Х. Туфан иҗатының төп сыйфатларын белү. Лирик геройның рухи баюын күрә белү. Туфан поэзиясенең әдәбиятыбыз өчен әһәмияте.

ӘТ – Шигырь строфасы һәм строфика. Авторның татар шигыре строфикасына керткән яңалыгын белү.

Әмирхан Еники.Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты белән таныш булу. *«Әйтелмәгән васыять»* хикәясендәге Акъәби образына салынган идея. Хикәянең сәнгатьчә эшләнеше, композициясендәге үзенчәлекләргә бәя. Ярдәмче образларга салынган вазифаны билгеләү.

“Рәшә” һәм “Саз чәчәге” повестьлары.  Тоталитар система шартларында үрчегән кимчелекләрне, аларның кеше рухына зыян салуын, шәхесне зәгыйфьләтүен сурәтләүгә багышланган әсәрләрнең татар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгели алу. Повесть геройлары холкындагы үзенчәлекләрне бүгенге көн күзлегеннә чыгып бәяли белү.

Әдәбиятка яңа иҗат көчләре килү. Г. Ахунов, Х. Вахит, Ш. Галиев, Х. Камал, Ә. Маликов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Т. Миңнуллин, В. Нуруллин, Н. Фәттах, И. Юзеев, М. Хәсәновһәм башкаларның әсәрләрендә кеше шәхесен гәүдәләндерүдә, кешенең җирдәге урынын ачыклауда яңалык билгеләре, психологизмга игътибар арту ; форма өлкәсендә яңалыклар.

Г.Ахунов “Хәзинә” романы. Романның идея-эстетик эчтәлеген белү. Төп образларга бәя бирә алу, аларның сурәтләнешендә үзенчәлекләрне, уңай якларын һәм кимчелекләрен күрсәтә алу.Романның бу чор татар әдәбияты һәм сәнгате өчен әһәмияте.

Н.Фәттах..Н.Фәттахның тәрҗемәи хәле белән таныштыру һәм иҗатына күзәтү ясау. Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы. Төп образлары, сюжет үстерелеше, характерларның ачылу дәрәҗәсе ягыннан үзенчәлекләре. Борынгы төрки халыклар тарихының бүгенге укучыга тәэсир итәрлек яклары, милли колоритны чагылдыру .

ӘТ - Тарихи роман, тарихилык принцибы.

А. Гыйләҗев. А.Гыйләҗевнең иҗатына күзәтү ясау “Өтәч меннгән читәнгә”. Әсәрдә уздырылган төп фикерне ачыклау, образларга бәя бирү, художество үзенчәлекләрен күрсәтә белү. Повестьның соңгы еллар әдәбияты өчен яңалыгы.

М.Мәһдиев. М.Мәһдиевнең “Кеше китә - җыры кала” повестен өйрәнү. Әсәрнең сәнгатьчә үзенчәлекләрен (сурәтләүдә күпбизәклелек, «тартмалы композиция» принцибына корылган булу, аның уңай һәм кайбер кимчелекле яклары) белү. Стиль үзенчәлекләрен күрә алу.

ӘТ - Әдәбиятның иҗтимагый вазифасы.

Ә.Баянов “Сәяхәтнамә” поэмасы Язучының тормыш юлы һәм иҗаты. Поэмага анализ.Әдипнең кеше һәм табигать мөнәсәбәтен фәлсәфи тирәнлек белән сурәтләве, табигатьне саклау мәсьәләләрен үткен итеп куюы.

И. Юзеев Әдип иҗаты турында гомуми мәгълүмат бирү. Шагыйрь һәм драматург буларак иҗат эшчәнлеге. Поэма, баллада, шигъри трагедияләре турында мәгълүмат. «Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмасындагы тормышчан проблемаларны күрә, алар турында үз фикерен җиткерә алу. Фазылҗан, Нур һәм «мин» образларының үзенчәлекләрен билгеләү. Кәккүк, юл образына йөкләнгән мәгънә. Җанлы һәм җансыз табигать образларының (көймә, урман, чабыш атлары) хатирәләрне тергезүдәге роле.

Т.Миңнуллин.Т.Миңнуллин әсәрләрендә яшәешнең әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләре күтәрелүе, буыннар арасындагы рухи бәйләнешнең югалу куркынычын хәбәр итеп чаң сугылуы, киләчәгебез турында борчылуы төрле нюансларда сәнгатьчә сурәтләнүе, шулар аша әдип шәхесен, аның кешелек сыйфатларын, талантын танып-белү.

Т.Миңнуллин. “Әлдермештән Әлмәндәр”. Пьесаның төп конфликтын, темасын, проблемасын белү. Персонажларның характер үзенчәлеген һәм авторның аларны гәүдәләндерү, җанландыру, комик һәм шул ук вакытта моңсу-пошынулы ситуацияләр тудыру осталыгын танып-белү.

ӘТ – пролог, эпилог, интермедия, аллегория.

Хәзерге татар әдәбияты.Җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылуын аңлата белү. Әсәрләрдә милли бәйсезлек һәм мөстәкыйльлеккә омтылу авазлары, милләтебез тарихына игътибарның артуы, тарихи һәм табигатьне саклау темаларының активлашуы. Бүгенге әдәбиятта шәхес концепциясенең үзенчәлекләре.

Поэзия.Гамил Афзал, Н.Арсланов, Ш.Галиев шигырьләре ярдәмендә хәзерге поэзиядә яңа тема һәм идеяләр калкып чыгуы, аерым жанрларның активлашуы, аерым жанр чикләрен киңәйтергә һәм төрләндерергә омтылулар . Шигъри сүзнең эчке куәтен, җегәрен арттыруда уңышлар . Поэзиядә халык иҗатындагы, бөтендөнья әдәбияты һәм сәнгатендәге символикадан, шартлы алымнардан файдаланырга омтылышның артуын һәм җанлануы.

Р.Фәйзуллин. Әдип иҗаты турында гомуми мәгълүматларны белү (кешенең рухи халәтен, күңел тирбәнешләрен кыска, җыйнак итеп сурәтләүдә шагыйрьнең табыш һәм ачышлары). «Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр» поэмаларының идея-эстетик үзенчәлекләрен аңлата алу. Әдипләр иҗаты турында гомуми мәгълүматларны белү.

Р.Харис:«Ат иярләү», «Ант суы», «Җәлилчеләр» поэмалары, «Кеше» ораториясе.Шигъриятендә заманчалык рухы, фикер тирәнлегенә омтылыш, шагыйрьнең сәнгатьчә үтемле мөмкинлекләр эзләве.

М.Әгъләмов: «Онытма, Европа?..», «Тукайдан хатлар» поэмалары. Авторның классик формалардан оста файдалануы.Туган ил, халык һәм милләт язмышы турында фәлсәфи гомумиләштерүләргә ирешүе, халыкчан, җанлы, сәнгатьле фикерләү байлыгыннан тел-стиль сурәтләре алуы.

Проза.Проза жанрында җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте проблемасын яңача хәл иткән әсәрләр язылу турында белү. Тоталитар системаның шәхесне изүен, физик һәм мораль яктан мәсхәрәләвен, таптавын әдәби әсәрләр мисалында аңлата белү. Г. Ахунов, “Идел кызы”,М.Хәсәнов “Язгы аҗаган” әсәрләре.

М.Хәбибуллин “Кубрат хан”, романы Әсәрләрдә гомумкешелек кыйммәтләренә игътибар, аларны ил мәнфәгатьләре яктылыгында карау, илнең иминлеген, милләт язмышын алга чыгарып тасвирлау үзенчәлекләрен күрә алу. Сюжет җанлылыгы, образлары турында фикер йөртә, тарихи фактларга, мәгънәләргә, сүз-тәгъбирләргә игътибар.

Р.Мөхәммәдиев “Ак кыялартурындахыял” повесте. Повестьның сәнгатьчә үзенчәлекләре.

ӘТ - Сәнгатьчә дөреслек.

Драматургия.Хәзерге драматургиядә әхлак проблемаларына игътибарның артуы, татар халкының рухи сәламәтлеге мәсьәләләре чагылуы, шәхес һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтен төрле вариантларда сурәтләнүе, җәмгыятьнең бүгенге төзелешендә шәхес үсешенә мөмкинлекләр булмауны торган саен кыюрак күрсәтә башлауны яшь драматурглар З. Хәким, М. Гыйләҗев, Д. Каюмов, Р. Гыйззәтуллинпьесаларына нигезләнеп аңлату. Жанр төрләрендәге яңалыклар, сәнгатьчә дөреслеккә ирешү чаралары.

Р.Батулла. “Сират күпере”.Әсәргә мөстәкыйль рәвештә анализ ясау. Г. Тукай образын гәүдәләндерүдә яңалыклар, сәнгатьчә ачышлар, образлар системасы.

Р.Хәмид пьесалары. “Җиде баҗа” Драманың төп фикере, сәнгатьчә үзенчәлекләре, яңа алымнар куллануда табышлар. Күгәй, Дая, Дулат, Искәндәр образларына бәя бирә алу.

Бүгенге татар балалар әдәбияты. Ш.Галиев, Р.Миңнуллин иҗатлары. Бүгенге татар балалар әдәбиятындагы төп тема һәм проблемалар. Сурәтләү объектының мәктәп тормышыннан, пионер оешмаларындагы вакыйгалардан гаилә хәлләренә, бала яки яшүсмернең эчке дөньясына авыша баруы.